**МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.02.2016 № 21-41-5

Казан ш.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 14.11.2008 ел, № 21-41-78 боерыгы белән расланган Агымдагы финанс елында чыгымнар ягыннан Татарстан Республикасы бюджетын үтәү буенча операцияләрне төгәлләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Боерык бирәм:

1. “Агымдагы финанс елында чыгымнар ягыннан Татарстан Республикасы бюджетын үтәү буенча операцияләрне төгәлләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында” 14.11.2008 ел, № 21-41-78 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы белән расланган Агымдагы финанс елында чыгымнар ягыннан Татарстан Республикасы бюджетын үтәү буенча операцияләрне төгәлләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы бюджетыннан касса түләүләре, бу Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән түләү документлары нигезендә, агымдагы финанс елының соңгы эш көненә кадәр хәл ителә.»;

5 пунктны төшереп калдырырга;

7 пунктта:

беренче абзацта:

«Дәүләт предприятиеләренә, оешмалары һәм учреждениеләренә бүлеп бирелгән Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары средстволары” дигән сүзләрне “Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан бүлеп бирелгән средстволар” дигән сүзләргә алыштырырга, һәм “Дәүләтнеке булмаган предприятиеләргә, оешмалар һәм учреждениеләргә бүлеп бирелгән Россия

Федерациясе субъектлары бюджетлары средстволары № 40203” (алга таба - № 40203 счетлар) дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Агымдагы финанс елының № 40202 счетлардагы Татарстан Республикасы бюджеты средстволарының файдаланмый калынган калдыклары, агымдагы финанс елы тәмамланырга күп дигәндә ике эш калганда, “Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары средстволары” № 40201 баланс счетында (алга таба - № 40201 счет) ачылган Федераль казначылык хезмәтенең ТР буенча счетына Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын алучылар тарафыннан күчерелергә тиеш.”;

10 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

“Төгәлләнгән финанс елында Россия Федерациясе законы нигезендә түләүләрне хәл итүгә җибәрелгән Татарстан Республикасы бюджеты средстволары, түләү поручениеләрендә түләүне алучылар реквизитларының дөрес күрсәтелмәве сәбәпле, чираттагы финанс елында Россия банкы подразделениеләре ки кредит оешмалары тарафыннан № 40201 счетларга кире кайтарылган очракта, Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын алучылар Казначылык департаментына (аның территориаль бүлекләре) әлеге средстволарны аныкланган реквизитлар буенча күчерү өчен түләү документларын Казначылык дерпартаментына (аның территориаль бүлекләре) тапшыруга хокуклы.”;

түбәндәге эчтәлектәге 11 пунктны өстәргә:

«11. Чираттагы финанс елының гыйнвар аенда Россия Федерациясенең эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә эшчәнлек алып баручы Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын алучылар, әлеге эшчәнлекне финанс ягыннан тәэмин итү өчен, “Юридик затлар тарафыннан касса операцияләрен алып бару тәртибе һәм хосусый эшмәкәрләр һәм кече эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан касса операцияләрен алып баруның гадиләштерелгән тәртибе турында” 11 март, 2014 ел, № 3210-У Россия Банкы Күрсәтмәләре нигезендә, үзләре тарафыннан билгеләнеп, кассада саклана ала торган максималь дәрәҗәдә рөхсәт ителгән сумма чикләрендә, кассада тере акча средстволары калдыкларына (алга таба – тере акча средстволары калдыклары) ия булуга хокуклы.

Чираттагы финанс елының эш көннәре булмаган бәйрәм көннәрендә файдаланылмаган, чираттагы финас улының 1 гыйнварына тере акча средстволары калдыклары, “Тере акча бирү һәм кертү һәм аерым операцияләр буенча исәп-хисапларны хәл итү өчен средстволар” №40116 баланс счетында ачылган Федераль казначылык хезмәтенең ТР буенча идарәсе счетына, алга таба Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын алучылар өчен узган еллардагы дебиторлык бурычын кире кайтару өчен билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемен<br>ә күчерү максатыннан чыгып,

чираттагы финанс елының өченче эш көненнән дә соңга калмыйча кертелергә тиеш.

Бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тере акча средстволары калдыклары хисабына чираттагы финанс елының касса операцияләре чираттагы финанс елы өчен бюджет учеты һәм бюджет хисабында чагылдырылырга тиеш.”

2. Бу боерыкны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментына Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары - Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры М.Д.Фәйзрахмановка йөкләргә.

**Министр** **Р.Р.Гайзатуллин**